**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**2021 елның 10 ноябре** **№ 7**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 24 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Ошторма-Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Майская урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 24 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Майская урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Майская урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. 2021 елның 24 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Юмья авылы, Майская урамы, 25а йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар, туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Югары Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Югары Юмья авылының Железнодорожная, Майская, Подгорная урамнарында вак таш җәелгән юлларны төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (Югары Юмья авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар, колонкалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелек;

- чишмәләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү (ремонтлау) (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Югары Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. 5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Ошторма Юмья авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев